**Библиографический справочник/Библиографик белешмә**

С помощью активных читателей библиотеки был составлен библиографический справочник, призванный заинтересовать наших земляков, глубоко изучить их книги, воспитать подрастающее поколение на примере известных личностей нашего края.

Китапханәнең актив укучылары ярдәмендә безнең күренекле якташ язучыларыбыз белән кызыксыну, аларның язган китапларын тирәнтен өйрәнү өчен, яшь буынны үзебезнең җирлектәге танылган шәхесләре үрнәгендә тәрбияләү ниятендә библиографик белешмә төзелде.




**Гарифҗан Мөхәммәтшин**



Гарифҗан Мөхәммәтшин Садыйк улы 1941нче елның 12нче октябрендә Арбор авылында туган. 1957нче елда Арбор җидееллык мәктәбен, 1960нчы елда көмеш медаль белән Чепья урта мәктәбен тәмамлый. 1964нче елда Казан дәүләт педагогия институтының физика-математика факультетын тәмамлый, физика һәм производствога өйрәтү укытучысы белгечлеге ала. 1968-1975нче елларда — Чепья урта мәктәбенең физика укытучысы, укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары. 1975-1977нче елларда — Яңгул урта мәктәбе директоры.1977нче елның июлендә Г.Мөхәммәтшин хезмәт ияләре депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары итеп сайлана.

1991нче елдан — район хакимияте башлыгы урынбасары. Ул озак еллар дәвамында район тормышының социаль-мәдәни тармагына, төзелеш эшләренә җитәкчелек итте .

Г.Мөхәммәтшинның иҗатында җырлар аерым урын алып тора. Танылган композиторлар аның шигырьләренә 60тан артык җыр иҗат иттеләр

Тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. .

Г.С.Мөхәммәтшин 1989нчы елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителде. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Хезмәтләре өчен берничә медаль белән бүләкләнде. «РСФСРның халык мәгарифе отличнигы», Татарстан Мәгариф министрлыгының «Мәгарифне үстерүдәге хезмәтләре өчен» билгеләре иясе. 1991нче елда Татарстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелде. "Хезмәттәге Батырлык өчен" медале иясе (1985), 2008нче елда аңа С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия бирелә.

**Төп басма китаплары**

**Килегез, дусларым**...: шигырьләр. -Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. - 72 бит. - 2500 данә.

Шагыйрь туган як табигатен, бай рухлы, тырыш авыл кешеләренең эчке дөньясын сүрәтли.

**Уеннан уймак**: шигырьләр .- Казан: Татар. кит. нәшр., 1988 - 24 бит. -20 000 данә.

Китапта шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшинның кече яшьтәге мәктәп балалары өчен шигырьләре тупланды.